ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 50 от « 17 » март 2021 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының 2018 елның 30 ноябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган административ регламентларны раслау турында» 136 карары белән расланган Социаль наем шартнамәсе буенча гражданга муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш муниципаль районы прокуратурасының 17.02.2021 елның 17 февралендәге, № 02-08-02-2021 санлы протесты, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон (29.12.2017 ел, 438-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга мөрәҗәгать итүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә бирү мөмкинлеген беркетү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында " 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында " 2013 ел, 23 апрель, 275 нче карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең «Мамадыш муниципаль районы җирле

үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм тәртибен раслау турында " 2012 елның 20 июнендәге 1090 номерлы карары» нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының 2018 елның 30 ноябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган административ регламентларны раслау турында» 136 карары белән расланган Социаль наем шартнамәсе буенча гражданга муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3)Мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составы турында документлар күчермәләре (уллыкка (кызлыкка) алу турында Карар, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.);».

1.2. 2.5 пунктының 6 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 2.6 пунктының 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

1.4. 3.4.1 пунктының 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

1.5. Регламентка 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составы турында документлар күчермәләре (уллыкка (кызлыкка) алу турында Карар, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.);".

1.6. Регламентка 1 нче кушымтаның 5 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Мамадыш шәһәре
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М.Гарипов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОГРН 1051655091080